КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 20 декабрь г.Казань № 1196

Граждан хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестрын алып баруның федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәве һәм аларны тапшыру турында белешмәләрне алу функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органны билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Респуб-ликасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Граждан хәле актлары турында» 1997 ел, 15 ноябрь, ФЗ-143 нче Федераль законның $13^2$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын Граждан хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестрын алып баруның федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәве турында түбәндәге белешмәләрне алу функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы (алга таба – вәкаләтле орган, федераль мәгълүмат системасы) итеп билгеләргә:

тууны дәүләт теркәве турында белешмәләр һәм туу турында актлар язуына төзәтмәләр һәм үзгәрешләр кертү хакында белешмәләр;

үлүне дәүләт теркәве турында белешмәләр һәм үлү турында актлар язуына төзәтмәләр һәм үзгәрешләр кертү хакында белешмәләр;

никах теркәү һәм никахны өзүне дәүләт теркәве турында белешмәләр һәм никах теркәү һәм никахны өзү турында актлар язуына төзәтмәләр һәм үзгәрешләр кертү хакында белешмәләр;

ата булуны билгеләүне дәүләт теркәве турында белешмәләр һәм ата булуны билгеләү турында актлар язуына төзәтмәләр һәм үзгәрешләр кертү хакында белешмәләр;

исем үзгәртүне дәүләт теркәве турында белешмәләр һәм исем үзгәртү турында актлар язуына төзәтмәләр һәм үзгәрешләр кертү хакында белешмәләр.

2. «Граждан хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль законның $13^2$ статьясы нигезендә Вәкаләтле органга федераль мәгълүмат системасыннан белешмәләр алганнан соң аларны ведомствоара багланышлар кысаларында вәкаләтле органнарга һәм оешмаларга тапшырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 октябрь, 507 нче; 2006 ел, 18 апрель, 192 нче; 2006 ел, 21 апрель, 199 нчы; 2007 ел, 7 ноябрь, 621 нче; 2008 ел, 28 март, 196 нчы; 2008 ел, 2 октябрь, 720 нче; 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1042 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 март, 197 нче; 2011 ел, 13 сентябрь, 762 нче; 2012 ел, 16 март, 221 нче; 2012 ел, 24 март, 237 нче; 2012 ел, 6 август, 668 нче; 2012 ел, 26 декабрь, 1153 нче; 2013 ел, 31 гыйнвар, 54 нче; 2013 ел, 14 март, 161 нче; 2013 ел, 14 май, 323 нче; 2014 ел, 12 апрель, 238 нче; 2014 ел, 8 июль, 471 нче; 2014 ел, 8 август, 575 нче; 2015 ел, 10 август, 578 нче; 2015 ел, 24 декабрь, 969 нчы; 2016 ел, 22 гыйнвар, 32 нче; 2016 ел, 15 июнь, 405 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 702 нче; 2016 ел, 14 декабрь, 933 нче; 2017 ел, 2 май, 256 нчы; 2017 ел, 21 август, 595 нче; 2017 ел, 12 декабрь, 976 нчы; 2018 ел, 24 июль, 590 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3 пунктның 3.3.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Граждан хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль законның $13^2$ статьясы нигезендә Граждан хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестрын алып баруның федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәве турында мәгълүматлар ала һәм аларны вәкаләтле органнарга һәм оешмаларга тапшыра.».

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин